НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ

МИРАС

VII ТАТАР МУЗЫКАСЫ ФЕСТИВАЛЕ

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РТ

ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АКАДЕМИЧЕСКИЙ СИМФОНИЧЕСКИЙ ОРКЕСТР РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Нәҗип Җиһанов исемендәге “Мирас” VII Татар музыкасы фестивале катнашучыларын һәм кунакларын сәламләү сүзе

Кадерле дуслар!

Татарстан башкаласында милләттәшебез, күренекле композитор, талантлы оештыручы һәм XX гасыр татар музыкасы сәнгатенең иң эре эшлеклесе Нәҗип Җиһанов исемен йөртә торган “Мирас” VII Татар музыкасы фестивале катнашучыларын һәм оештыручыларын сәламләвемә ихлас күңелдән шатмын.

Республика халкы үзенең талантлы композиторлары данга күмгән күпгасырлык музыкаль традицияләре белән хаклы рәвештә горурлана. “Мирас” татар музыкасы фестивале – тыңлаучыларны милли иҗатның классик әсәрләре белән таныштыру өчен менә дигән мөмкинлек.

Шушы еллар дәвамында фестиваль республиканың мәдәни тормышында ныклап урнашырга өлгерде. Татарстанның уникаль милли-мәдәни колориты белән сугарылган үтә дә бай мәдәни мирасы төрле елларда иҗат иткән татар композиторларының иҗатында чагылыш таба һәм Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры башкаруында заманча яңгыраш ала.

Фестивальдә катнашучыларга уңышлар, саекмас илһам чыганагы һәм яңа музыкаль казанышлар, ә кунакларга – уңай хис-кичерешләр һәм онытылмаслык тәэссоратлар теләп калам!



Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Александр Сладковский

Татарстан Республикасының халык артисты, Россиянең халык артисты. Марис Янсон һәм Мстислав Ростроповичка ассистентлык итә, 2006-2010 елларда Юрий Башмет җитәкчелегендәге “Новая Россия” Дәүләт симфоник оркестрының дирижёры була. 2010 елдан - Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры (2021 елның 18 ноябрендә ТР ДСОна “Академия” исеме бирелә).

Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР Дәүләт академия симфоник оркестры - Medici.tv һәм Mezzo телеканалларында Россиядән беренче булып яздырылган төбәк коллективы. 2014 елда Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО Япониядә La Folle Journée фестивалендә катнашты. 2016 елда үзенең тарихында беренче тапкыр Европа туры кысаларында Брукнерхауста (Линц) һәм Мюзикферайнның Алтын залында (Вена) концертлар бирде. 2018 елның декабрендә ТР Дәүләт симфоник оркестрының Кытайга беренче гастрольләре узды. 2019 елда Франциянең Нант шәһәрендә ARTE телеканалы La folle journée фестивалендә коллективның концертын яздырып трансляцияләде. 2016 елда “Мелодия” тавыш яздыру компаниясе белән берлектә берничә глобаль музыкаль проект гамәлгә ашырылды: Г. Малерның өч симфониясе (№№ 1, 5, 9), шулай ук Д. Шостаковичның барлык симфонияләре һәм уен кораллары концертлары яздырылды. П.И. Чайковскийның тууына 180 ел тулуга багышлап, композиторның барлык симфонияләре һәм уен кораллары концертлары Sony Classical лейблында яздырылды, 2020 елның май аенда “Чайковский-2020” бокс-сетының цифрлы релизы тәкъдим ителде. 2020 елның августында Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО Sony Classical лейблында С. Рахманиновның барлык симфоник әсәрләрен яздырды. “Сергей Рахманинов. Симфоник коллекция” бокс-сетын тәкъдим итү концертлары 2021 елның мартында Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Казанда узды. 2021 елның июлендә Л. ван Бетховенның барлык симфонияләре һәм И. Стравинский балетларының музыкасы яздырылды. И. Стравинский язмаларының бокс-сетларын тәкъдим итү концертлары 2022 елның апрелендә Пермь, Мәскәү, Казан, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләрендә узачак.

Сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО хәзерге вакытта Мәскәү дәүләт филармониясендә үзенең еллык абонементы булган беренче һәм бердәнбер төбәк оркестры.

2021 елның 1 сентябрендә Н. Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Вадим Роберт улы Дулат-Алиев чакыруы буенча Татарстан Республикасының Александр Сладковский Н.Г. Җиһанов исемендәге КДКнең опера-симфоник оркестр белән дирижёрлык итү кафедрасы профессоры итеп билгеләнде.

2021 елдан башлап, Александр Сладковский Россия Музыкасы Академиясенең академигы, әгъзасы булып тора. Шулай ук 2021 елда ул Валерий Хәлилов хәйрия фондының попечительләр советына керде.

Татарстан Республикасының Дәүләт Академия Симфоник Оркестры

Татарстанда симфоник оркестрын оештыру идеясен беренче булып, Татарстанның Композиторлар берлеге рәисе, Казан дәүләт консерваториясе ректоры Нәҗип Җиһанов әйтә. Җиһанов һәм КПССның татар өлкә комитеты ның беренче секретаре Табеев башлангычы белән Казанга Натан Рахлин чакырып китерелә. 1979 елда Натан Григорьевичның вафатыннан соң, оркестр белән Ренат Салаватов, Сергей Калагин, Равил Мартынов, Имант Коциньш эшли. 1985 елда сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёр вазифасына Россиянең һәм Казах ССРның халык артисты Фуат Мансуров чакырыла, ул оркестрда 25 ел эшли. 2010 елда Фуат Шакир улы вафат булганнан соң, яңа сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер итеп, Россиянең атказанган артисты Александр Сладковский билгеләнә (2016 елдан Россиянең халык артисты, 2020 елдан Татарстан Республикасының халык артисты, 2021 елдан Н.Г. Җиһанов исемендәге КДКнең опера-симфоник оркестр белән дирижёрлык итү кафедарсы профессоры), Татарстанның Дәүләт симфоник оркестры 45 нче сезонын аның белән ача (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 18 ноябреннән 1102 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестрына “Академия” исеме бирелде. Оркестрның исеме “Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры” дәүләт автоном учреждениесе дип үзгәртелде).

Александр Сладковский килү белән оркестр тарихында яңа чор башланды. ТР Дәүләт академия симфоник оркестры тарафыннан оештырылган музыка фестивальләре – “Рахлин сезоннары”, “Ак сирень, “Казан көзе”, Concordia, “Денис Мацуев дуслары янында”, “Иҗади ачыш”, “Мирас”, Орган фестивале Татарстанның һәм Россиянең мәдәни тормышындагы олы вакыйгалар булып танылды. Оркестр музыка мәктәпләрендә һәм консерваториядә укучы талантлы балалар һәм студентлар өчен “Республика казанышы” проектын, Казанның мәктәп укучылары өчен “Оркестр белән музыка дәресләре” һәм “Оркестрның тылсымлы кыллары” дигән уку-укыту проектлары, инвалидлар һәм авыр хәлдәге балалар өчен “Музыка белән дәвалау” хәйрия проектларын булдырды.

ТР ДАСОның иҗади партнерлары арасында Ильдар Абдразаков, Борис Андрианов, Борис Березовский, Игорь Бутман, Аида Гарифуллина, Хибла Герзмава, Вероника Джиоева, Пласидо Доминго, Барри Дуглас, Симона Кермес, Сергей Крылов, Василий Ладюк, Николай Луганский, Миша Майский, Денис Мацуев, Михаил Плетнев, Эдвард Радзинский, Вадим Репин, Сергей Ролдугин, Максим Рысанов, Чулпан Хаматова, Дмитрий Хворостовский, Николай Цнайдер, Суми Чо, Альбина Шаһиморатова кебек танылган башкаручылар һәм мәдәният эшлеклеләре бар.

Төрле елларда оркестр Юрий Башмет, Владимир Альтшулер, Михаэль Гюттлер, Кен-Дэвид Мазур, Кристофер Мулдс, Андрес Мустонен, Кшиштоф Пендерецкий, Марк Пиолле, Владимир Спиваков, Эрнст Тайс, Владимир Федосеев, Дмитрий Юровский, Кристиан Ярви, Фредди Кадена һ.б. бик күп дирижёрлар белән хезмәттәшлек итте.

Александр Сладковский җитәкчелегендәге

ТР Дәүләт академия симфоник оркестры - Medici.tv һәм Mezzo телеканалларында Россиядән беренче булып яздырылган төбәк коллективы. 2014 елда Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО Япониядә La Folle Journée фестивалендә катнашты. 2016 елда үзенең тарихында беренче тапкыр Европа туры кысаларында Брукнерхауста (Линц) һәм Мюзикферайнның Алтын залында (Вена) концертлар бирде. 2018 елның декабрендә ТР Дәүләт симфоник оркестрының Кытайга беренче гастрольләре узды. 2019 елда Франциянең Нант шәһәрендә ARTE телеканалы La folle journée фестивалендә коллективның концертын яздырып трансляцияләде.

2012 елда оркестр Sony Music һәм RCA Red Seal лейблларында ике альбом яздырды, ә 2016 елда “Мелодия” тавыш яздыру компаниясе белән берлектә берничә музыкаль проект гамәлгә ашырылды: Г.Малерның өч симфониясе (№№ 1, 5, 9), шулай ук Д. Шостаковичның барлык симфонияләре һәм уен кораллары концертлары яздырылды. П.И. Чайковскийның тууына 180 ел тулуга багышлап, композиторның барлык симфонияләре һәм уен кораллары концертлары Sony Classical лейблында яздырылды, 2020 елның май аенда “Чайковский-2020” бокс-сетының цифрлы релизы тәкъдим ителде. 2020 елның августында Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО Sony Classical лейблында С. Рахманиновның барлык симфоник әсәрләрен яздырды. “Сергей Рахманинов. Симфоник коллекция” бокс-сетын тәкъдим итү концертлары 2021 елның мартында Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Казанда узды. 2021 елның июлендә Л. ван Бетховенның барлык симфонияләре һәм И. Стравинский балетларының музыкасы яздырылды. И. Стравинский язмаларының бокс-сетларын тәкъдим итү концертлары 2022 елның апрелендә Пермь, Мәскәү, Казан, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләрендә узачак.

Александр Сладковский җитәкчелегендәге оркестрның концертларының язмалары “Орфей”, "BBC Radio 3" радиоларында һәм “Культура” телеканалында даими рәвештә трансляцияләнә.

Сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР ДАСО хәзерге вакытта Мәскәү дәүләт филармониясендә үзенең еллык абонементы булган беренче һәм бердәнбер төбәк оркестры.

Вадим Дулат-Алиев

Вадим Дулат-Алиев – сәнгать гыйлеме докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең ректоры, Нәҗип Җиһанов исемендәге “Мирас” татар музыкасы фестиваленең арт-директоры. “Мирас” фестиваленең арт-директоры буларак, Дулат-Алиев аның концепциясен һәм программасының эчтәлеген билгели.

Россиянең абруйлы музыка белгечләренең берсе, рус һәм татар музыкасын өйрәнүче, методолог, Казан консерваториясендә музыкаль әсәрләр анализы буенча әйдәп баручы профессор. Милли мәдәният тексты теориясенең авторы, әлеге теория хәзерге заман шартларында милли сәнгать үсешен аңлата.

Балалар музыка мәктәпләре һәм музыкаль колледжлар өчен татар музыка әдәбияты буенча беренче дәреслекне, татар музыкасы буенча беренче фонохрестоматияне төзүче. “Татар музыкасы гасыры - Татарстан аһәңнәре” музыкаль-мәгълүмати интернет-порталын булдыру буенча проектның авторы һәм җитәкчесе. “Моңлы сүзем” I музыкаль-шигъри иҗат интернет-фестивале” проектының авторы һәм җитәкчесе.

Казан музыка училищесын экстерн рәвештә, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый, Мәскәү консерваториясендә аспирантура да укый, шунда докторантура-стажировка үтә, Мәскәүдә “Милли муызкаль мәдәният текст буларак: XX гасырда татар музыкасы” дигән темага докторлык диссертациясен яклый һәм Россия Федерациясендә үз белгечлеге буенча иң яшь сәнгать белеме докторы, соңрак профессоры да була.

1993 елдан алып, Казан консерваториясендә эшли. Озак еллар фән буенча проректор була, татар музыкасы, теориясе һәм тарихы кафедрасы белән җитәкчелек итә. 2021 елның июненнән югары уку йортының ректоры.

Россия Федерациясенең Музыкаль белем бирү буенча укыту-методик берләшмәсе президиумы эшендә катнаша, 2010-2012 елларда П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең “Музыка гыйлеме” белгечлеге буенча Дәүләт аттестацион комиссиясен җитәкли, Мәскәү консерваториясенең, Гнесиннар исемендәге Россия Музыка академиясенең, КФУның фәнни журналларының редакцион коллегиясе әгъзасы булып тора.

Татар музыкасы тарихы буенча хезмәтләр циклы өчен Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлыкның премиясе иясе; Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе мәдәният министры В.Р. Мединскийның Рәхмәт хаты (2019), Россия Федерациясе мәдәният министры О.Б. Любимованың Рәхмәт хаты (2020) белән бүләкләнгән.

НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ «МИРАС» VII ТАТАР МУЗЫКАСЫ ФЕСТИВАЛЕ

9 февраль 18:30

Туган як.
Мансур Мозаффаров музыкасы
Композиторның тууына 120 ел тулу уңаеннан

Татар темаларына увертюра
(Си-бемоль мажор, 1938)

“Галиябану” операсыннан сәхнәләр:
Кереш, Галиябану арияләре,
Бию, Бәдри җыры

Мулланур Вахитов истәлегенә
симфоник поэма

Татар темаларына увертюра
(Ре мажор, 1938)

“Көй” оркестр белән виолончель өчен
(А. Луппов орк.)

Җырлар:
“Җиләк җыйганда” (М. Җәлил шиг.),
“Туган як” (М. Мазунов шиг.)

Оркестр белән скрипка өчен
концерт № 1

Солистлар
Ильяс Камал (виолончель)
Динә Хисанбаева (скрипка)
Диләрә Төхвәтуллина (сопрано)
Алмас Хөсәенов (тенор)
Руслан Закиров (баритон)

Дирижер
Ринат Халитов

12 февраль 17:00

Чит илләрдә татар һәм мөселман дөньясының заманча музыкасы
Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

Т. Шаһиди (Таҗикстан, Россия)
«Садо» («Аваз»)
Симфоник поэмасы

Л. Хамиди (Казахстан)
Казакъ вальсы

Р. Брандангер (Норвегия)
«Зәңгәр күл».
Оркестр белән альт өчен сүзсез җыр

М. Бяшимов (Төрекмәнстан)
Оркестр белән фортепиано өчен
концерт «Demim»
(«Минем сулышым»)

М. Шәмсетдинова (АКШ)
«Тамгалар» симфоник циклы

А. Ишморатов (Канада)
Оркестр белән виолончель өчен
концерт №2 (Россиядә премьера)

Солистлар
Илүсә Хуҗина (сопрано)
Айдар Баһаветдинов (альт)
Денис Алиев (фортепиано)
Василий Степанов (виолончель)

Дирижер
Айрат Ишморатов

НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ “МИРАС” VII ТАТАР МУЗЫКАСЫ ФЕСТИВАЛЕ

16 февраль 18:30

Рәшит Кәлимуллин.
Симфоник биюләр
Композиторның 65 яшенә

«Симфоник биюләр»

«Петербург новеллалары»
симфоник сюита

Ингуш биюләре

Җырлар:
“Мин Татар!”,
“Тормышыма кайт, син, ямьләнеп”,
“Оныт инде”,
“Кайчан гына очрашырбыз”

Оркестр белән саксофон өчен
концерт (2, 3 өлешләр)

«Казан тарихлары»
симфоник картиналар

«Җир Планетасы» симфониясе
(Тугызынчы симфония, премьера)

Солистлар
Мария Шумарина (саксофон)
Ильгиз Мөхетдинов (тенор)
Айгөл Гардисламова (сопранно)

Дирижер
Айрат Кашаев

Мансур Мозаффаров

Татар темаларына увертюра, «Галиябану» операсына сәхнәләр, оркестр белән виолончель өчен «Көй» (А. Луппов орк.), «Җиләк җыйганда» җыры, «Туган як» җыры, «Мулланур Вахитов истәлегенә симфоник поэма», оркестр белән скрипка өчен Концерт № 1

Мансур Мозаффаров – күренекле татар композиторы, педагог, фольклорчы – 1902 елның 6 мартында Казанда туган. Иҗади эшчәнлеген халык уен кораллары ансамбльләрендә катнашучы буларак башлаган. 1931 елда Мәскәү консерваториясенең этнографик бүлеген А. Александровта композиция классы буенча тәмамлаган. 1934 - 1938 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә белем алган. 1945 елдан башлап, Казан консерваториясендә укыткан, 1949-1961 елларда шунда ук композиция кафедрасына җитәкчелек иткән. Төрле елларда радиода, Татар опера һәм балет театрында иҗади эшчәнлек алып барган.

М. Мозаффаровның композиторлык мирасы киң колачлы: халык көйләрен камил дәрәҗәдә эшкәрткән үрнәкләрдән һәм җырлар, романслардан алып, опера, симфоник поэмалар, уен кораллары концертларына кебек киң масштаблы югары сәнгать әсәрләренә кадәр. Симфоник партитураларда композитор халык җырларының гына түгел, ә халыкның уен коралларында уйнау үзенчәлекләрен, татар музыка уен кораллары тембрының үзенчәлекле аһәңнәрен киң һәм күп төрле итеп куллана.

М. Мозаффаров иҗатының зур бер өлешен вокал музыкасы тәшкил итә. Халык музыкасының теле, күпгасырлык халык авыз иҗаты традицияләре Мозаффаровның композиторлык фикерләү рәвешенә үтеп кергән һәм аның музыкасында халыкныкын авторныкыннан аерып алу җиңел түгел: әлеге башлангычлар шулкадәр табигый һәм сизелмәс дәрәҗәдә бер-берсенә үрелеп бара. Бу композиторның җыр-романслар иҗатында аеруча тулы чагылыш таба.

Композиторның тематикасы һәм характеры ягыннан төрле җырлары аһәңлелектә яңалыгы, якты лиризмы, шигырь ритмикасына үтеп керү нечкәлеге, көенең тәэсирлелеге, аһәң һәм гармония байлыгы белән җәлеп итә. Моның иң матур үрнәкләренең берсе булып Мөнир Мазунов шигыренә иҗат ителгән “Туган як” җыры тора.

Татар темаларына увертюра 1938 елда языла. Увертюраның тематик нигезен ике халык җыры тәшкил итә: кырый өлешләрендә - “Җизнәкәй” шаян җыр-диалогы, урта өлешендә - “Кәккүк” лирик җыры. Увертюра

Мансур Мозаффаров иҗатының башлангыч чорында иҗат ителүенә карамастан, ул истә кала торган, үзенчәлекле, анда композиторның өлгергән стиленә хас сыйфатлар чагылыш таба.

«Галиябану» операсыннан сәхнәләр. Композитор музыкаль театр үсешенә аның әле формалашу вакытында ук зур өлеш кертә: 1939 елда ул "Галиябану" операсын иҗат итеп төгәлли (икенче редакциясе - 1966 елда язылa). Опера Мирхәйдәр Фәйзинең шул исемдәге драмасы буенча язылa, өч пәрдәдән, дүрт картинадан тора. Премьерасы 1940 елда Галиәсгар Камал исемендәге Татар академия театрында була. Әлеге әсәрнең төп сыйфатларыннан аның халык җырларына таянуын һәм музыкаль теленең аңлаешлы булуын билгеләргә мөмкин - "Галиябану" фольклор материалны цитата рәвешендә мулдан кулланып иҗат ителгән.

«Галиябану» – иң популяр татар пьесаларының берсе, 1916-1917 елларда язылган, беренче тапкыр 1922 елда нәшер ителгән. Пьеса гүзәл Галиябану белән көндәше, бай улы Исмәгыйль тарафыннан үтерелгән ярлы Хәлилнең мәхәббәт тарихы турында сөйли, шул ук вакытта ул социаль гаделсезлеккә, дини хорафатларга протест белдерү булып та яңгырый.

Мансур Мозаффаровның «Көй» әсәре фортепиано белән скрипка өчен язылa, 1970 елда нәшер ителә.

2002 елда композиторның тууына 100 ел тулу уңае белән А.Б. Луппов тарафыннан ул яңадан эшкәртелә һәм симфоник оркестр белән виолончель өчен оркестровка ясала.

«Җиләк җыйганда». Мансур Мозаффаров Муса Җәлилнең "Җиләй җыйганда" дигән шигыренә иҗат иткән әлеге җыр күптән инде татар музыкасы классикасы булып киткән. Лирик җырның темасы - яшь кызның мәхәббәт хисләрен аңлатуы.

«Мулланур Вахитов истәлегенә симфоник поэма». Әсәр 1957 елда язылган. Фидакарь революционер-ленинчы М. Вахитов истәлегенә багышланган поэмада автор инкыйлаб җырларының аһәңнәрен бик оста файдалана, алар мантыйкка ярашлы рәвештә тыңлаучыга "Смело, товарищи, в ногу" җырының яңгырашын хәтерләтә.

Оркестр белән скрипка өчен Концерт № 1. М. Мозаффаров – татар музыкасында скрипка концертлары авторларының берсе. Биредә аңа табигатьне, оркестрның тәэсирлелек мөмкинлекләрен, аерым уен коралларын, бигрәк тә скрипканы яхшы белүе ярдәм итә, автор скрипка өчен бик күп төрле көйләр иҗат итә. Композициянең классик принципларына нигезләнеп, Мозаффаров гаҗәеп бер үзенчәлекле әсәр тудыра. Бигрәк тә аның икенче өлеше ихласлыгы белән арылып тора. Ул гаҗәеп чиста һәм тирән музыка, ул үзенең самими, риясыз ихласлыгы һәм эчкерсезлеге белән әсир итә. Аның концерт эстрадасында мөстәкыйль пьеса буларак, еш яңгыравы очраклы түгел һәм ул һичшиксез татар музыка уен кораллары лирикасының иң гүзәл сәхифәләренең берсе булып санала.

Ильяс Камал

Ильяс Камал — композитор, виолончельдә уйнаучы, аранжировка ясаучы. 1992 елда Санкт-Петербургта туган. 2011 елда Казанның И.В. Әүхәдиев исемендәге музыка көллиятен тәмамлый. (Татарстан Республикасының халык артисткасы Л. Маслова классы). 2016 елда Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый (Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты, профессор А. Әсәдуллинның виолончель классы, Татарстан Республикасы һәм Мордовия Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе профессор Б. Трубинның һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, доцент В. Харисовның композиция классы).

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының баш дирижёры. Казанның "La Primavera" камера оркестры дирижёры. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең, Филармония музыкаль-әдәби лекторий солисты. Татарстан Республикасының Дәүләт кыллы квартеты солисты. Россия Федерациясе Композиторлар берлеге һәм Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге әгъзасы.

Татарстан Республкиасының төрле коллективлары һәм солистлары тарафыннан башкарыла торган күп санлы әсәрләр, шулай ук аранжировкалар һәм оркестровкалар авторы. Алар арасында: Казанның "La Primavera" камера оркестры, “Яңа музыка” Камера оркестры, Казан консерваториясенең "Tatarica" оркестры, ТР Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, "Sforzando" башкару сәнгате үсеше фонды оркестры, "Alqanat" рок-төркеме.

Динә Хисанбеева

Динә Хисанбеева — Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең скрипка кафедрасында өлкән укытучы. Д.Д. Шостакович исемендәге Курган музыка көллиятен тәмамлаган (РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре Г.И. Кушвид классы). 2016 елда - Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә ассистентура-стажировка үтә (П.И. Чайковский һәм И. Бочкова исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе профессоры классы). В. Третьяков, Э. Грач, Г. Муржа, Э. Шмидер кебек танылган музыкантларның мастер-классларында катнашканы бар. “Көньяк-Урал - Зальцбург” Халыкара конкурс-фестиваленең Гран-при иясе, «Viva Music» Халыкара конкурсы (Казан, 2011), II Бөтенроссия кыллы уен коралларында уйнаучылар конкурсының (Казан, 2013), II Бөтенроссия музыкаль конкурсының КДК квартеты составында (Мәскәү, 2015) лауреаты, III Бөтенроссия конкурсының Фортепиано Триосы номинациясендә лауреаты (Мәскәү, 2019). Turksoy җыелма халыкара камера оркестры артисты (Төркия, 2012).

2016 елдан Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең скрипка кафедрасында укыта. 2017 елдан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының артисты һәм солисты.

Конкурсларда, фестивальләрдә, концертларда, мастер-классларда катнаша.

Актив рәвештә концерт һәм педагогик эшчәнлек алып бара.

Диләрә Төхвәтуллина

Диләрә Төхвәтуллина (1997 елда туган) — сопрано. 2013 елдан 2017 елга кадәр И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә вокал факультетында укыган (Казан консерваториясе доценты, ТРның халык артисты, РФнең атказанган артисткасы К.А. Хәйретдинова классы). 2017 елдан Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең вокал факультетында белем ала (К.А. Хәйретдинова классы).

Диләрә Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестиваленең I дәрәҗә лауреаты (2021 ел), «Татар моңы» Халыкара яшь башкаручылар конкурсының I дәрәҗә лауреаты (2021 ел).

Алмас Хөсәенов

Алмас Хөсәенов – Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе солисты.

Башкортстан Республикасы Баймак районының Казанка авылында туган.

Сибай сәнгать көллиятен тәмамлаган (Д.М. Ласынов классы). Хәзерге вакытта укуын Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә профессор З.Д. Сөнгатуллина классында дәвам иттерә.

“БДБ илләре арасында Яшьләрнең Дельфий уеннары” конкурсының “Алтын медале” иясе.

Ә. Афзалова исемендәге Халыкара конкурсның, Р.Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры конкурсының Гран-при иясе.

“Татар моңы” Халыкара конкурсрының, “Идел” Халыкара татар-башкорт җыры конкурсының 1 нче дәрәҗә лауреаты.

Ринат Халитов

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен “Халык уен кораллары”, “Халык уен кораллары оркестры белән дирижёрлык итү” белгечлекләре буенча тәмамлаган (1982, 1985).

1983 елдан Казан консерваториясендә укыта башлый, ә 1999 елдан алып, 2002 елга кадәр “Опера-симфоник оркестр белән дирижёрлык итү” белгечлегенә Россиянең халык артисты, профессор Фуат Мансуровта ассистентура-стажировкада укый.

1993 елдан Казан дәүләт консерваториясендә Tatarica оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры булып тора. Аның җитәкчелегендә коллектив Италиядә халыкара конкурслар лауреаты (1995 ел), Франциядә Гран-при иясе (1997 ел) һәм Россия Федерациясе Президентының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге Грантына ия була (2000 ел).

Хәзерге вакытта Ринат Халитов - Казан консерваториясе музыкаль театр кафедрасы профессоры. Дирижёр сыйфатында консерватория каршындагы опера студиясенең Н. Җиһановның “Түләк”, Т. Гыйззәтнең “Наемщик” пьесасы буенча музыкаль драма, Г.

Камалның “Хафизәләм, иркәм!” пьесасы буенча С. Сәйдәшевның музыкаль драмасы, Җ. Фәйзинең “Башмагым” музыкаль комедиясе, Э. Низамовның “Алтын Казан” опера-риваяте (Ренат Харис либреттосы), Е.Анисимовның “Раштуа төне” опера-колядасы, М. Шәмсетдиновaның “Җир уллары трагедиясе”, М. Яруллинның “Кеше” ораториясе (Ренат Харис либреттосы) кебек спектакльләрендә һәм концерт программаларында катнаша.

Толибхон Шаһиди
«Садо» («Аваз») симфоник поэмасы

Толибхон Шаһиди (1946) – совет чоры, Россия һәм таҗик композиторы. 1972 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлаган - Арам Хачатурян классы. 1987 елда Нью Джерсида (Глазборо, АКШ) узган заманча музыка халыкара конкурсы лауреаты, Таҗикстанның Рудаки исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Таҗикстанның халык артисты. Россия Композиторлар һәм кинематографистлар берлеге әгъзасы. Мәскәү Композиторлар берлегенең алтын медале иясе (2012 ел), Бельгиядә узган Халыкара кинофестиваль лауреаты.

П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң, Т. Шаһиди иҗади эшчәнлеген туган Дүшәнбе шәһәрендә башлый, анда күпсанлы симфоник әсәрләр иҗат итә. Алар арасында иң күренеклесе - “Садо” (“Аваз”) симфоник поэмасы 1984 елда языла.

“Садо” әсәренә кереш өлешендә Т. Шаһиди Шашмаком циклыннан “Бузрук” мәкам көен циатта итеп ала, анда ул затлы итеп, тромбоннарда яңгырый. Тулаем алганда, “садо” - купшы яңгырашлы, шул ук вакытта драматик үсеше булган әсәр.

«Садо» — исерткеч һәм ялкынлы ритмнарның, лампидар унисоннарның, кабатлана торган гипнозлы көйләрнең өермәсе, дулкынландыргыч картинасы. Боларның барысы да тылсымга төрә, дәртле биюләрне тыйнак кына күзәтеп торган җиреннән, дәрте ташып, сикереп төшеп биегән кеше кебек сихерле. Һәм бу оркестрның мөмкинлекләрен бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән композиторның осталыгыннан тора. Беренче карашка, бәрмә уен кораллары белән бакырга басым ясала кебек. Бирედә бернинди консонанслы аккордлар да юк: унисон һәм гетерофония генә бар. Диапазондагы өзелешләр чиксез пространство тойгысын бирә; яңгырашның ләззәтле куәте буйсынмас стихияләр белән ассоциацияләргә китерә.

Латыйф Хәмиди

Казах вальсы

Латыйф Хәмиди (1906-1983) – композитор, казах профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе, Алма-Ата консерваториясендә укытучы, Казах ССРның халык артисты. Казан губеринясенең Бүәле авылында (хәзерге Кайбыч районының Ябалак авылы) татар гаиләсендә туган.

Латыйф Хәмиди Беренче музыка техникумын (Б.Л. Яворскийда) һәм Мәскәү Консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен (Г.И. Литинский классы) тәмамлаган. Казах театрында музыка бүлеге мөдире һәм композитор, Казах дәүләт капелласында җитәкче һәм дирижёр, Алма-Атада казах халык уен кораллары җитәкчесе, Алма-Ата консерваториясенең халык уен кораллары кафедрасы мөдире булып эшли.

Латыйф Хәмиди “Абай” һәм “Түләгән Тохтаров” (А. Жубанов белән берлектә), “Джамбул һәм Аукумыс”, “Джамбул” операларын иҗат итә, драма спектакльләренә һәм фильмнарга көйләр, камера һәм симфоник әсәрләр яза. Казах ССРның Дәүләт Гимны авторларының берсе булып тора. Композитор иҗатының зур бер өлеше Казахстан белән бәйле булуга карамастан, ул беркайчан да үзенең тамырларын онытмый һәм татар шагыйрьләренең шигырьләренә дә җырлар яза, шулай ук үзенең әсәрләрендә татар көйләрен дә куллана.

Казахстанда Латыйф Хәмидинең музыкасын яраталар һәм беләләр. Республиканың һәрбер кешесе диярлек аның С. Мукановның “Ике бәйрәм” радиопьесасына язган “Казах вальсы” белән таныш. Әлеге вальс 1940 елда иҗат ителә - ул казах милли музыка сәнгатендә беренче вальс. Шаян, сыгылмалы, нечкә, нәфис аһәңле бу көй Латыйф Хәмидинең үзенең дә, Казахстанның башка композиторларының да аннан соң язган вальсларына нигез булып тора.

Хәмиди - бик үзенчәлекле шәхес, чөнки ул казах милләтеннән булмаса да, иҗатында казах моңнарын бирә алган иҗатчы.

Рушана Брандангер

«Зәңгәр күл». Оркестр белән альт өчен сүзсез җыр

Рушана Брандангер (Хәйбуллина) – композитор, продюсер, аранжировка ясаучы, җырчы. Казанда туган, Казан консерваториясе каршындагы Махсус урта музыка мәктәбендә А. Ибушеваның скрипка классында һәм Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә профессор К. Монасыйповта альт классында укыган. 1998 елдан Татарстанның Дәүләт симфоник оркестры артисты була, 2009 елда Бергенның филармония оркестрына конкурс аша тыңлауларга үтә.

Р. Брандангер – Гамбргта үткән "Романсиада" (2017) рус романслары башкаручыларның халыкара конкурсының Гран-при иясе. Норвегиядә романслар кичәләре оештыручы һәм башкаручы, Берген Милли операсының опера музыкасы фестивале артисты.

Р.Брандангер әсәрләре арасында: рус һәм Норвегия шагыйрьләре шигырьләренә язылган романсларның ике җыентыгы, симфоник миниатюралар, камера оркестры өчен, ансамбль өчен танго стилендә 8 альттан торган әсәрләр. Инглиз һәм рус телендә джаз рок, hiphop, soul кебек төрле стильдәге популяр җырлардан торган ике альбом, шулай ук «Stories of the imagination» дигән уен кораллары музыкасы альбомын чыгарган.

Композитор үз әсәре хакында менә нәрсәләр сөйли: "Зәңгәр күл урнашкан урын - әкияттәге бер ил кебек, ул бу дөньядан аерым яши. Чишмә суы кебек саф су муызкада арфа аша чагылыш таба, күлнең тоирәнлеге һәм гүәллеге - оркестрда, ә тынычлык һәм тынып калу - альт солосында".

Мердан Бяшимов

Оркестр белән фортепиано өчен концерт «Demim» («Минем сулышым»)

Мердан Бяшимов (1985) – Төрекмән ССРда туган, Төрекмәнстанның бөек бакши ыруыннан, җиденче буын музыкант. Балачагыннан ук музыкага һәвәс була, башта - дутарда, аннан соң фортепианода уйнарга өйрәнә. Укыганда ук, төрле халыкара һәм милли конкурсларда катнаша, “Яңа исемнәр” Халыкара хәйрия фондында өч тапкыр стажировка үтә.

Композиция һәм оркестровка буенча беренче дәресләрен Альфред Шниткеның бердәнбер шәкерте Рәҗәп Аллаяровтан ала. 2005 елдан профессиональ дәрәҗәдә аранжировка белән шөгыльләнә. 8 ел дәвамында “Нуран” (Төрекмәнстан) джаз коллективында клавишник һәм аранжировка ясаучы була һәм Россиягә, чит илләргә гастрольләр белән йөри.

2017 елда Мердан Бяшимов Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый (ТАССРның һәм Мордовия Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Б.Н. Трубинның композиция классы).

Композиторның симфоник һәм камера әсәрләре Мәскәүдә, Казанда, Ярославльдә, Сочида, Саранскта, Ашхабадта, Ташкентта яңгыраганы

бар. Кышкы халыкара сәнгать фестивале (Сочи, 2018) кысаларында Альфред Шнитке һәм Святослав Рихтер истәлегенә үткән IV яшь композиторлар конкурсы лауреаты, Б. Барток исемендәге Халыкара композиция конкурсы дипломанты (Будапешт, 2018), La Primavera камера оркестры өчен иң яхшы әсәргә Бөтенроссия ачык конкурсы лауреаты (Казан, 2018), Альфред Шнитке һәм Святослав Рихтер истәлегенә үткән V яшь композиторлар конкурсының I премиясе лауреаты (Сочи, 2019), X Яшь композиторлар академиясенең стипендиаты (Чайковский шәһәре, 2020).

Pro-Sound Music (Мәскәү, 2020) һәм MusicHeads (Мәскәү, 2021) тавыш режиссурасы курсларында һөнәри әзерлек үткән.

«Demim» төрекмән теленнән “минем сулыш” дип тәрҗемә ителә. Dem — сулыш, мизгел, рух.

«Бәләкәй чактан ук музыка яратам. Ул һәрвакытта да миңа нык тәэсир итә иде, хәзер дә бөтен тормышыма йогынтысы зур. Балачакта берәр төрле көй ишетеп, радио яки телевизор каршында катып калган чакларым да булгалый иде.

“Демим” әсәре күпмедер дәрәҗәдә минем өчен балачак хыялы кебек, яки еллар буе җыелып килгән хатирәләр дисбесе. Анда минем музыкага карата мөнәсәбәтем, аңа табынуым, безнең үзара тәэсиребез чагыла. Мин аны үземнең музыкаль биографиям дип атар идем...

Бу пьесаны язганда, мин нindидер яңа нәрсә уйлап чыгарырга омтылмадым, тыңлаучыны шаккатырыйм әле, игътибарын җәлеп итим әле дип тырышмадым. Мин рәхәтлек кичердем. Мин ноталарга күңелемдәге һәм эчке көемдәге музыкаль яңгырашны салдым, мин шулардан эстетик ләззәт алам. Махсус рәвештә партияләрдә катлаулы алымнар кулланмадым, бәләкәй бала исеменнән сөйләнә торган шушы кыска гына хикәямә кагылу теләсә кайсы башкаручы өчен уңайлы булсын дип тырыштым. Һәркем - тыңлаучы да, башкаручы да озак еллар күңелемдә йөргән шушы халәтне тойсын дип теләдем. Балачакта туган яктылыкны без гомер буена үзебезнең күңел түрендә йөртәбез бит. Бу бала чагында ук музыкага гашыйк булган һәм хәзер дә гашыйк булып яшәүче олы яшьтәге сабыйның хикәяте.

Биографик яктан бу әсәр - консерваториядә язган әсәрләремнең соңгысы. Мин Борис Николаевич Трубинда укыдым, һәм бу пьеса күпмедер дәрәҗәдә - остазым белән, консерватория белән хушлашу, тормышымның бер этабына йомгак ясау. Бу әсәрне язганда, мин шатлык хисләрен дә, бер үк вакытта сагыш хисләрен дә кичердем, гүя Реквием иҗат иттем.

Ни өчен соң бу әсәремне “Сулыш” дип атадым?

Фортепиано партиясенең беренче аккордларын уйнаганда, һәркайсы алдыннан тирән итеп сулыш ала идем, ә сулышны чыгарганда, аккордка ияреп, күңелемнең бер өлеше дә аерылып чыга иде”.

Мәсгудә Шәмсетдинова
«Тамгалар» симфоник циклы

Мәсгудә Шәмсетдинова (1955 елда туган) – Татарстан Респбуликасының атказанган сәнгать эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты. Казан консерваториясен тәмамлаган (профессор А.Б. Лупповның композиция классы). Казан курчак театрының музыка бүлеге мөдире, Казан телевидение студиясендә музыкаль тапшырулар мөхәррире, Казан консерваториясендә фольклор лабораториясе мөдире булып эшли. Озак еллар дәвамында элекке Советлар Союзы авылларында, Швеция, Төркия, Америка һәм башка илләрдә татар диаспораларында фольклор экспедицияләрендә йөри. Кинофильмнарга һәм спектакльләргә язган музыкасы өчен премияләр һәм махсус бүләкләр иясе. Ул төрле жанрларда иҗат итә - җырлар, ораторияләр, балетлар, симфонияләр.

2002 елда АКШка күчеп китә, www.tatarica.com дигән интернет радио ача, анда тәүлек әйләнәсенә төрки фольклор музыкасы һәм татар композиторларының әсәрләре яңгырый.

Фольклор өлкәсендә даими рәвештә тикшеренү эшләре - хәзерге вакытта композиторның фәнни эшчәнлек өлкәсе. Ул бишек җырлары җыя, лекцияләр укый, музыка белемен укыта. 2005 елның 24 июнендә аның музыкасы астында Казанда тантаналы рәвештә Кол Шәриф мәчете ачылды.

М. Шәмсетдинова үзенең әсәре турында: “Гасырлар уза, ата-бабаларымның күңел кыллары инде чиртүдән туктаган, әмма алар кузгаткан хисләр тамгаларда сугылып калган. Тамга - символ, мөһер һ.б. - күчмә халыклар дөньясында географик яктан яки вакытлар аша бер-берсеннән аерылган ыруларны, нәселләрне бәйли торган билге. Мәсәлән, безнең ыуның тамгасы - өч япьле корал.

Моң - Тамга! “Моң” сүзен күп төрле итеп шәрехләп була. Аны этносның генетик коды сеңгән “беренчел аваз” дип тә тәрҗемә итәргә була. Нәкъ менә шуңа бәйле кытай пентатоникасын татар пентатоникасыннан аерып була.

Моң - Тамга, аваз аша хәтерне уяту юлы буларак, “мин кем?” дигән сорау аша үземне эзләү һәм табу формаларында гәүдәләнеш таба.

Безне әйләндереп алган бөтен авазлар - музыка. Хәтта тынлыкның да үз көе бар. Усак яфраклары шаулаганда, тавыш калтырану ишетелә, яңгыравык пиццкато астында өй чикерткәсе таҗларның сыгылмалылыгын татып карый, барабан тавышы бакыр төсендә ялтырый... Константин Бальмонт әйткән сүзләрне үзгәртеп: “Мин - мәңгелек җил, мин мәңге җырлыйм, җырлаганда, мин һәрвакытта да яз”, - дип әйтәсе килә.

Бала чагымның курганнары күз алдыннан үтә. Чыпчык, очып чык (Чыпчык, очып чык - нәниләргә авазлар уены, Дәү Әни — Бөек ана, Арба шыгырдый - ул мине ата-бабаларымның чишмәләренә алып бара...

Моң-Тамга, туган телемнең фонемалары мине әйләндереп алган хаосны тәртипкә сала, ул минем Аваз дигән могҗизага тартылуыма ачыклык кертә”.

Айрат Ишморатов

Оркестр белән виолончель өчен концерт №2 (Россиядә премьера)

Айрат Ишморатов – Канада композиторы, дирижер һәм кларнетист. Милләте белән татар. Лаваль Университеты профессоры (Квебек).

Казан дәүләт консерваториясенең кларнет классын тәмамлаган, аннан соң Монреаль Университетында кларнет һәм композиция классы буенча магистр дәрәҗәсе, опера-симфоник оркестр белән дирижёрлык итү классы буенча докторлык дәрәҗәсе алган. Канаданың Квебек мәдәниятенә керткән өлеше өчен бирелә торган Prix Charles Biddle премиясе лауреаты (2020).

Айрат Ишморатов әсәрләре Chandos (UK), Warner Classics (USA), Analekta (CA), ATMA Classique (CA), Hedone Records (UK) лейблларында яздырылган.

Айрат Ишморатовның, чакырылган дирижёр буларак, дөньяның бик күп оркестрлары белән чыгыш ясаганы бар. Шулай ук “Les Violons du Roy” (2007-2009) Камера оркестры резиденциясендә һәм Квебек симфоник оркестры резиденциясендә (2009-2012) дирижёр була. 2011 елның августында Айрат Ишморатов “I Musici de Montreal” камера оркестрының турнесына дирижёр итеп чакырыла, Бразилия, Перу, АКШ һәм Канадада була. Айрат Ишморатов популяр “Клезтори” (Kleztory) клезмер төркеме 2000 елда оешканнан алып, аның сәнгать җитәкчесе һәм кларнетчысы булып тора, шуннан бирле дөньяның 20 илендә меңнән артык концерт биргән һәм 6 диск яздырган.

Хәзерге вакытта Айрат Ишморатов Виктор Гюгоның “Көлә торган кеше” романы мотивлары буенча “L'Homme qui rit” операсын иҗат итә, опера Festival Classica (Montreal) заказы буенча языла, премьерасы 2023 елның җәенә планлаштырыла.

Оркестр белән виолончель өчен концерт №2 2018 елда Канада виолончелисты Стефан Тетро һәм Orchestre de la Francophonie заказы буенча языла һәм беренче тапкыр 2018 елның 21 июлендә Стратфорд (Канада) шәһәрендә башкарыла. Концерт 3 өлештән тора: Grave/Andante - Largo - Allegro con brio, шулай ук үз эченә тулаем виолончель солосы каденциясен дә ала, ул исә үзе бер тулы канлы өлеш булып тора. Айрат Ишморатовның концертында, бигрәк тә икенче һәм өченче өлешләрендә рус композиторларының йогынтысы сизелә.

Илүсә Хуҗина

Илүсә Хуҗина 1987 елда Яр Чаллы шәһәрендә туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанда И.В. Әүхәдиев исемендәге музыка көллиятенә (училище) укырга керә. 2008 елда аны яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт Консерваториясенә вокал факультетына килә (академик җыр). Училищеда да, консерваториядә дә Илүсә Хуҗина Казан консерваториясе доценты, ТРның халык артисткасы, РФнең атказанган артисткасы К.А. Хәйретдиновада укый.

Консерваториядә укыганда, ул Казахстанның Семипалатинск шәһәрендә узган "Иртыш таңнары" XI Халыкара татар сәнгате фестивалендә Гран-прига (2010), Яшь башкаручыларның "Татар моңы" II Халыкара телевизион фестивалендә II дәрәҗәдәге дипломга (2010) ия була; 2012 елда Моцартның "Фигаро туе" операсында Сюзанна партиясен башкара, дирижер Лео Кремер (Германия) һәм шул ук елның августында Риминида (Италия) вокал сәнгате курслары (Associazione Culturale Artistica Enarmonica) ала. 2013 елда кызыл диплом белән консерваторияне тәмамлый. 2013 елда И. Кальманның "Сильва" опереттасында Стасси партиясен башкара. Германиядә Кельн Музыка һәм биюләр югары мәктәбендә магистратурада укыр алдыннан (2013-2015, профессор Клаудия Кунц-Айзенлор) Прагада опера җырчысы, сәнгать магистры Таһира Менаждиновадан мастер-класслар ала.

2013 елның декабрендә Берлин филармониясендә Илмар Лапиньш (Латвия) дирижерлык иткән Берлин симфоник оркестры белән Раштуа концертында чыгыш ясый. 2014 елда Кельнда Кшенекның "Диктатор" операсында Шарлотта партиясен һәм Ахен дәүләт театрында (Германия) Моцартның "Уйлап чыгарылган бакчачы кыз" операсында Сандрина партиясен уңышлы итеп башкара.

Универсиадага әзерлек чараларында катнашканы өчен Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның Истәлек медале белән бүләкләнгән. 2015 елның июлендә Казанда Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатын ачу тантанасында чыгыш ясады. 2015 елның сентябрендә маэстро Игорь Яковлевич Крутой белән аның иҗат кичәсендә җыр башкарды. 2016 елда Vissi D Arte Халыкара опера җырчылары конкурсында (Прага, Чехия) һәм "Үзгәреш җиле" татар җыры фестивалендә лауреат булды. Норвегия, Япония, Кытай, Мисыр, Израиль, Германия, Чехия, Голландия, италия, Латвия, Литва, Эстония, Төркия, Украина, Кыргызстан, Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Монголия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Финляндия, АКШ, Испания илләрендә чыгышлар ясаганы бар.

Айдар Баһаветдинов

Казанда туган. 2001 елда Казан дәүләт консерваториясе каршындагы урта махсус музыка мәктәбен тәмамлаган (ТРның һәм РФнең атказанган укытучысы Хәбибуллина О.Б.ның альт классы). 2006 елда Н.Җиһанов исемендге Казан дәүләт консерваториясен кызыл дипломга тәмамлый (доцент, ТРның һәм РФнең атказанган укытучысы Хәбибуллина О.Б.ның альт классы, доцент Французова Н.Г.ның камера ансамбле классы, өлкән укытучы Виват Ю.Ю.ның квартет классы). 2011 елда Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең аспирантурасын тәмамлый (Монасыйпов К.Х. җитәкчелегендә). 2008 елның гыйнварыннан Монреаль университетында (Université de Montréal, Канада) СССРның халык артисты, Сталин премиясе лауреаты Цыганов Д.М. шәкерте, профессор Туровская Э.А. классында, Канаданың альт ассоциациясе президенты, Hochschule für Musik in Vienna тәмамлаган профессор Юта Пушхамер-Сиделионың квартет классында укуын двам иттерә. 2009 елның сентябрендә магистр дипломына ия була.

2011 елдан ТР Дәүләт аадемия симфоник оркестрының солисты булып тора.

2012 елдан Н.Җиһанов исемендге Казан дәүләт консерваториясенең ансамбль һәм кыллы квартет кафедрасында укыта.

“Яңа исемнәр” I Бөтенроссия яшь муызкантлар ачык конкурсы лауреаты (Мәскәү, 2000); “Муызка, Яшьлек, Өмет” VII Халыкара фестивале дипломанты (Петрозаводск, 2001); IV Халыкара кыллы уен коралларында уйнаучылар конкурсы лауреаты (Тольятти, 2002); III Бөтенроссия камера ансамбльләре конкурсы лауреаты (Сызрань, 2003); Шостакович исемендәге VII халыкара квартетлар конкурсы лауреаты (Монреаль, Канада, 2008); “Рус башкару сәнгате” фонды стипендиаты, “Яңа исемнәр фонды стипендиаты, Татарстан республикасы президентының махсус стипендиясе; Танеев исемендәге Халыкара камера ансамбльләре конкурсы лауреаты (Калуга, 2014).

Түбәндәге оркестрларда уйнаган: 2004 ел - Россия студентлар симфоник оркестры, дирижер Александр Сладковский (Санкт-Петербург); 2005, 2006 – Яшьләр симфоник оркестры (Тольятти), дирижер Россиянең атказанган артисты России Анатолий Левин, Үзбәкстанның милли смифоник оркестры дирижеры Владимир Неймер; 2008 –"Schleswig-Holstein Music Festival" оркестр академиясе, дирижер Кристоф Эшенбах (Christoph Eschenbach), Германия; 2010 – "The World Orchestra", дирижер Жозеф Висент (Joseph Vicent), Испания; шулай ук дирижерлар Жан Франсуа Риве (Jean-François Rivest), Бломштадт (Blomstedt), Лоуренс Фостер (Lawrens Foster), Генрих Шиф (Henrich Schiff), Михаил Плетнев җитәкчелегендәге оркестрларда.

Денис Алиев

Пианист, композитор, аранжировка ясаучы. Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. 2019 елдан Мәскәүдә яши.

Мәктәптә укыганда ук, Татарстан композиторларының балалар өчен фортепиано музыкасын иң оста башкаручы булып танылa. «Арт-форум», «Light of Kazan» (эстрада-джаз уен коралында соло башкару номинациясендә), "Бартоломео Кристофори" VII Халыкара конкурсы (Санкт-Петербург шәһәре) халыкара конкурслары лауреаты. Хәрби оркестрларның Кызыл Мәйданда узган "Спас манарасы" Халыкара фестивалендә, Кремль сараенда "Җиңү язы алдыннан" программасында, "Казань Арена"да узган "Arena Land" Кышкы фестивальдә һ.б. да катнашучы. Эре музыкаль шоуларда катнашудан тыш, академик музыка өлкәсендә концертлар эшчәнлеге алып бара. Репертуарында И.С. Бах, В.А. Моцарт, Л. Бетховен, Ф. Шопен, Ф. Лист, Э Григ, С.В. Рахманинов, С.С. Прокофьев, Д.Д. Шостакович, Ф. Пуленк һ.б. әсәрләре бар. Күп тапкырлар Казан консерваториясенең һәм Тынлы уен кораллары оркестры белән чыгышлар ясаганы бар. Клавир импровизация тарихын өйрәнә, фәнни конференцияләрдә докладлар белән чыгышлар ясый, фәнни язмалары бар.

Василий Степанов

1994 елда Казанда туган. 2018 елда П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясен тәмамлаган (Натлия Шаховская, Борис Андрианов классы). 2018-2020 елларда Мадридта Королева Софиянең Югары музыка мәктәбендә стажировка үтә (Йенс Петер Майнц классы). Хәзерге вакытта Гнесиннар исемендәге Россия музыка академиясендә укыта.

Валерий Гаврилин исемендәге Губернатор халыкара үсмерләр конкурсы (Вологда, 2010; I премия), Святослав Кнушевицкий исемендәге Халыкара виолончелистлар конкурсы (Саратов, 2012; II премия), "Талантлар йолдызлыгы" Халыкара конкурсы (Чабаксар, 2012; Гран-при), Е.А. Мравинский исемендәге Халыкара үсмерләр конкурсы (Санкт-Петербург, 2012; I премия), Riga Classic Strings халыкара конкурсы (2018; I премия), Бөтенроссия муызка конкурсы (Мәскәү, 2018; II премия) лауреаты. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы стипендиаты.

Сергей Ролдугин, Давид Герингас, Йенс Петер Майнц, Мартти Роуси, Нильс Ульнер, Торлейф Тедеен мастер-классларында, шулай ук Карл Нильсен исемендәге халыкара мастер-класста (Ассенс, Дания) катнашканы бар.

Актив рәвештә концерт эшчәнлеге алып бара. Россиядә дә, чит илләрдә дә, шул исәптән Нью-Йортның Линкольн-үзәгендә чыгыш ясый. "Элисо Вирсаладзе тәкъдим итә..." фестивалендә катнашучы. Александр Сладковский, Кристиан Кнапп, Эдуард Грач, Максим Федотов, Теодор Курентзис, Михалис Экономy, Джулиан Галант, Рөстәм Абязов, Алексей Воронцов һ.б. дирижёрлар белән хезмәттәшлек итә.

2012 елның Санкт-Петербург Музыка йорты программаларында катнашучы.

Рәшит Кәлимуллин

«Симфоник биюләр», «Петербург новеллалары» симфоник сюита, Ингуш биюләре, Җырлар: “Мин Татар!”, “Тормышыма кайт, син, ямьләнеп”, “Оныт инде”, “Кайчан гына очрашырбыз”, Оркестр белән саксофон өчен концерт (2, 3 өлешләр), «Казан тарихлары» симфоник картиналар, «Җир Планетасы» симфониясе (Тугызынчы симфония, премьера)

Рәшит Кәлимуллин – күренекле композитор, Россия Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге рәисе, Россиянең һәм Татарстан Республикасының халык артисты, җәмәгать эшлеклесе. Россия Композиторлар берлеге әгъзасы (СССР).

Рәшит Кәлимуллин әсәрләре Европа илләрендә, АКШта, Япония, Кытай, Израильдә һәм Россия шәһәрләрендә - Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан һ.б яңгырый. Аның әсәрләрен башкаручылар арасында: Россия милли оркестры, Санкт-Петербург филармониясенең Академия симфоник оркестры, шулай ук Германия, Швеция, Израиль, Испания, Англия, Колумбия, АКШның алдынгы оркестрлары.

Әсәрләре А. Дмитриев, Ф. Мансуров, М. Плетнев, А. Ведерников, Л. Николаев, А. Скульский, А. Сладковский, Р. Нигъмәтуллин (Россия), В. Матюхин (Украина), Дж. Галлант (Бөекбритания), Ф. Мастранджело (Италия), А. Берин (Германия), Тимоти Филлипс (Австралия), Герассим Воронков (Испания), Томас Слиппер (АКШ), Зое Зениоди (Греция-АКШ) һ.б. дирижёрлар җитәкчелегендә яңгыраганы бар.

Рәшит Кәлимуллин – 2009 Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмебелән оештырылган һәм уңышлы гамәлгә ашырылган "Рус һәм татар музыкасы энҗеләре" симфоник концертлар проектының авторы һәм җитәкчесе. Әлеге проектка нисбәтле Татарстан композиторларының музыкасы беренче тапкыр Германия, Швеция, Италия, Израиль, Испания, Австралия, Колумбия, Англия һәм россиянең иң яхшы залларында яңгырады.

Рәшит Кәлимуллин. Симфоник биюләр. Композиторның 65 яшьлегенә" концерты композиторның бөтен дөньяда башкарыла торган иң гүзәл, иң популяр әсәрләрен тәкъдим итә.

«Симфоник биюләр» (2017 ел). "Симфоник биюләр" циклына композиторның "Аккош" балетыннан иң гүзәл номерлар керде: "Хәвефле иртә", "Танго", "Баллада".

«Петербург новеллалары» симфоник сюитасы (2018 ел). Композитор өчен Санкт-Петербург — ул ярата һәм үзенең әсәрләре иң яхшы залларда башкарыла торган шәһәр, шул ук вакытта - ул аның эчке виртуаль дөньясының бер шәһәре. Композитор шәһәрне үзенчә төсләрдә күрә - хәвефле дулкынландыргыч, кайчак тантаналы бөек, ә кайчагында Фин култыгыннан искән җиләс һава аңа хыяллар һәм өметләр алып килә.

«Дарида» һәм «Сай-воцар» ингуш биюләре (2019 ел). Композитор ингушларның иң популяр биюләрен үз версиясендә иҗат иткән. Ингуш халык биюләрен башкару традицияләре турында менә нәрсәләр мәгълүм: "Ингушларда кияүгә чыккан хатын-кызлар биемәгән. Кызларга гына биергә ярагаан. Моңа өстәп, ингушларда шундый бер ышану да булган: кияүгә чыккан хатын-кыз чит кеше белән өч тапкыр биеп әйләнсә, аның никахы таркалган. Биюләр үзенә күрә кыз сайлау да булган. Биюдә яшьләрнең этикет кагыйдәләрен ни дәрәҗәдә белүе һәм мәдәнилеге дә күренгән. Аякларын тиз-тиз йөртеп, егет кеше әйләнәләр ясый, шунда аның җитезлеге дә, виртуозлыгы да күренә. Ул көтмәгәндә генә йөзеп кенә китеп барган кыз каршына килеп чыга. Монда инде һәркем матуррак, дәрәҗәлерәк, яхшырак булырга омтыла..."

Оркестр белән саксофон өчен концерт (2014 ел). Концерт үз жанры өчен гадәти түгел: икенче өлеше ихлас, лирик. Саксофон кеше тавышы белән елый, һәрбер нотаны тирән кичерешләр белән тутыра. Концертның финалыннан тамашачыларга да күчә торган энергия ташый.

Җырлар:

"Кайчан гына очрашырбыз" – Н. Касыймов сүзләре.

"Оныт инде" – Р. Вәлиев сүзләре.

"Мин татар!" – Г. Хафизов сүзләре.

"Тормышыма кайт, син, ямьләнеп" – Р. Шиһапов сүзләре.

Солистлар - Айгөл Гардисламова һәм Ильгиз Мөхетдинов.

«Казан тарихлары» симфоник картиналары (2020 ел).

«Әлеге музыка шәһәр белән күзгә-күз аралашулардан туды. Мин Казанны иртә таңда, яктыра башлаган вакытында аеруча яратам. Шушы мизгелдә күптавышлы тулы бер оркестр булып, кошлар сайрый башлый, һәркайсы үз җаена. Кояш нурлары көч туплый, һәм һава гүя

зыңлап тора. Мин урамга чыгам да шәһәр буйлап китәм. Бу вакытта урамда беркем дә очрамый. Шәһәр әле уяна гына. Һәм шундый мизгелләрдә мин үткәннәрдән картиналар күрәм кебек тоела. Менә Кабан күле янына беренче кешеләр килеп, көнкүрешләрен корып җибәрә, авыр хезмәт белән яшәү өчен шартлар тудыра. Буыннар алмашына... Казансу ярындагы калкулыкта болгарлар Кирмән төзи, соңрак ул Казан ханлыгының Кремле булып китә. Сугышлар уза, кешеләр үлә. Бу шәһәр күпме кешеләрнең кайгыларын күргән, күпме хыянәт, комсызлыкны кичергән, күпме батырлык һәм вөҗданлылыкны биргән! Тыныч һәм чәчәк ату чорлары булган, тынлык һәм хәвефле чорлар узган. Шәһәрдә яңа йортлар барлыкка килгән, ул йортлар торган саен биегрәк була барган. Боларның барысы да гармония телендә минем “Казан тарихлары” дигән әсәремдә чагылыш тапты. Әмма әйтәсе килгән төп фикерем, төп хисләрем, кадерле тыңлаучылар – халкымны ярату.

“Казан тарихлары”ның йомгаклау өлешендә мин һәрбер татарның йөрәгендә кайтаваз булып яңгырый торган халык җырларыннан өзекләр китерәм. Халкыбыз шушы җырлар белән үзенең телен, мәдәниятен, кем булуын саклап калган, һәм әгәр дә милли идеяне музыка аша яңгыратып булса, ул “Су буйлап” дигән татар халык җыры булыр иде – аннан да гүзәлрәк, кадерлерәк һәм якынрак берни дә юк, ул һәр йөрәккә ачкыч! Сез боларның барысын да минем музыкамда ишетерсез һәм сүз белән әйтеп булмый торган нәрсәләрне йөрәгегез белән тоярсыз дип ышанам”. Рәшит Кәлимуллин.

Симфония №9 “Җир планетасы" (дөньякүләм премьера). 2021 елның августында композитор Рәшит Кәлимуллин “Җир планетасы” симфониясен тәмамлый. Бу - күп өлештән торган симфоник елъязма, анда безнең планетаның бүгенге проблемалары чагылыш тапкан.

Композитор чынбарлыкны нечкәрәк, җетерәк төсләрдә кабул итә, шуңа да аның җавабы газаплырак, фаразлары, күзаллавы төгәлрәк. Автор бездән соңгы буыннарга калдырасы Җирнең киләчәгенә, аның табигатенә битараф түгел. Ул кешелек кыйммәтләренең бөтен системасына һәлакәт янау ихтималлыгы турында кисәтә.

Шул ук вакытта аның дөньяны күзаллавы Җир чикләреннән дә узып китә. Рәшит Кәлимуллин галәмнең йөрәк тибешен тоя, ул планетаны Яралтучы кулларындагы бер энҗе бөртеге кебек итеп күзәтә. Ул бөтен нәрсәгә ярату белән карый, шуңа да аның һәлакәтнең булмый калуына иманы нык, һәм ул кешелек “Югары Акыл” кануннары буенча алдынгы үсеш этабына аяк басачак дип ышана.

“Җир планетасы” дигән симфония шактый озак вакыт языла. Бу авторның айлар буена камилләштергән олуг хезмәте.

“Җир планетасы” симфониясенең идеясе һәм аны гамәлгә ашыру - уникаль, Татарстан Республикасы композиторларының мондый әсәр иҗат иткәне юк иде әле.

Мария Шумарина

Мария Шумарина - саксофончы, педагог, Бөтенроссия тынлы ансамбльләр конкурсы лауреаты (2014), “Виват-Казан!” Халыкара балалар, үсмерләр, яшьләр һәм өлкәннәрнең иҗат коллективлары һәм башкаручыларның фестиваль-конкурсы лауреаты (2014, 2015), сәнгать гыйлеме кандидаты.

1998 елдан алып, 2002 елга кадәр Казан музыка училищесында эстрада-джаз бүлегендә укый. 2007 елда Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең (академиясенең) оркестр бүлеген тәмамлый. 2010 елда Казан дәүләт консерваториясенең аспирантурасында укып чыга (Санкт-Петербург консерваториясе доценты Большиянова А.Ю. классы).

2011 елдан Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә эшли, 2019 елда “Доцент” гыйльми дәрәҗәсе бирелә. 2014 елдан тынлы башкару тарихы буенча лекцияләр курсын алып бара.

Солистка буларак, Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры, “La Primavera” камера оркестры, “Орфей” радиосы Дәүләт симфоник оркестры, А. Шутиков җитәкчелегендәге Дәүләт халык уен кораллары оркестры, Казан консерваториясенең Тынлы уен кораллары оркестры, “Татарика” халык уен кораллары оркестры, “Яңа музыка” оркестры, Башкортстан Республикасының Милли симфоник оркестры белән чыгыш ясаганы бар.

Күпсанлы конкурсларда жюри әгъзасы, алар арасында “Алтын көз” III Бөтенроссия фестиваль-конкурсы, “Уңыш факторы Бөтенроссия балалар, үсмерләр һәм өлкәннәр иҗаты фестиваль-конкурсы, “Музыка балкышы” XV Күпжанрлы башкару осталыгы төбәк конкурсы, “Виктория” VI Халыкара балалар һәм үсмерләр иҗаты конкурс-фестивале, “Раштуа әкияте” Халыкара конкурсы һ.б. бар.

Ильгиз Мөхетдинов

Ильгиз Мөхетдинов 1994 елда Казанда туган. Мәктәптә укыганда, беренче сыйныфтан ук ТРның атказанган мәдәният эшлеклесе Ибәтуллин Рамиль Мөнир улында вокал дәресләре ала. Мәктәптән соң, Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенә татар халык җырлары бүлегенә укырга керә (Хәбибуллина Эльвира Солтан кызы классы). Көллият тормышында актив катнаша, Гәрәева Венера Хәсән кызы җитәкчелегендәге хорда солист була.

2020 елда Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең вокал классын тәмамлый (Татарстан Республикасының атказанган артисткасы Хәбибуллина Эльвира Солтан кызы классы).

Казан консерваториясендә укыганда, опера студиясендә солист була. 2018 елдан Филүс Каһировның концерт труппасында. 2020 елда Татар дәүләт филармониясенә чакырыла. “Татар моңы” халыкара конкурс-фестиваль лауреаты (2013 ел), Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивале лауреаты (2017 ел).

Айгөл Гардисламова

Айгөл Гардисламова - И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятен (ТРның халык артисты, РФнең атказанган артисткасы К.А. Хәйретдинова классы) һәм Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Опера студиясе солисты буларак, “Наемщик”, “Түләк” “Аршин мал алан”, “Цирк принцессасы” һ.б. спектакльләрдә партияләр башкара. Җырчының репертуарында чит ил, рус, татар арияләре һәм җырлары бар, эстрада әсәрләрен дә башкара. “Үзгәреш җиле”нең өч сезонында да катнашты. Халыкара һәм Бөтенроссия конкурслары лауреаты. И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте педагогы.

Айрат Кашаев

Россия күләмендә билгеле дирижер Айрат Кашаев 1984 елның 23 ноябрендә Казанда туган. 2004 елда И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесын яхшы билгеләренә генә тәмамлый, аннан соң укуын П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясендә “хор белән дирижерлык итү” белгечлеге буенча профессор Л.З. Конторовичта һәм “опера-симфонияләр белән дирижерлык итү” белгечлеге буенча Г.Н. Рождественский классында (2009 һәм 2012 елларда кызыл дипломга бетерә) дәвам иттерә. 2009 елда Айрат II Бөтенроссия хор дирижёрлары конкурсында I премия лауреаты була. Консерваторияне “Елның иң яхшы укучысы – 2012” исеме белән тәмамлый.

Чакырылган дирижёр буларак, Айрат Кашаев Мәскәү консерваториясенең Концерт симфоник оркестры, Мәскәүнең Яшьләр камера оркестры, С.В. Рахманинов исемендәге Симфоник оркестр, Ярославль академия губернатор симфоник оркестры, Липецк симфоник оркестры, “Яңа музыка” камера оркестры, Татарстан Республикасының камера оркестры, Мәскәүнең “Геликон-Опера” музыкаль театры, “Мәскәү опереттасы” Театры коллективлары белән эшли.

2008 елдан 2017 елга кадәр Айрат Кашаев - Г.П. Вишневская исемендәге Музыка-театр сәнгате көллияте театрының баш дирижеры, 2015 елдан – “Таврида” Бөтенроссия белем бирү форумының симфоник оркестрында сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер. “Таврида кайтавазы” яшь композиторларның, музыка белгечләренең, музыкантларының музыкаль академик ассамблеясенең сәнгать җитәкчесе (2017). XIX Бөтендөнья яшьләре һәм студентлары фестивале (Сочи, 2017) кысаларындагы Дөнья яшьләр симфоник оркестрының авторы, сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры. “Тынычлыкка мәдхия” (Липецк, 2018) халыкара фестиваленең баш дирижеры.

Дирижерның репертуарында П. Чайковский, Н. Римский-Корсаков, Г. Перселл, Э. Хумпердинк, В-А.Моцарт, Б. Бриттен, Дж. Верди, Ф. Пуленк, Дж. Перголези, К. Орфа опералары, И. Дунаевский, И. Штраус опереттлары, П. Чайковский, И. Стравинский, В. Гаврилин балетлары, шулай ук А. Корелли, С. Бах, Л. Бетховен, В-А. Моцарт,Й. Гайдн, Ф. Шуберт, Р. Шуман, Ф. Мендельсон-Бартольди, И. Брамс, А. Дворжак, П. Чайковский, С. Рахманинов, С. Прокофьев, Д. Шостакович, Е. Подгайц, М. Броннер, Ю. Холопов, Р. Мурсякаев симфонияләре һәм концертлары һәм башка әсәрләр бар.

Сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер
АЛЕКСАНДР СЛАДКОВСКИЙ

Беренче скрипкалар төркеме

1. **Алина Яконина - оркестр концертмейстеры, беренче скрипкалар концертмейстеры, Татарстан Республикасының атказанган артисткасы**
2. **Николай Усанов - беренче скрипкалар концертмейстеры**
3. **Максим Монасыпов - беренче скрипкалар концертмейстеры**
4. **Олег Мороз - беренче скрипкалар концертмейстеры**
5. Асия Гареева
6. Тимур Монасыпов
7. Евгения Захарова
8. Наталья Новикова
9. Тимур Гилязутдинов
10. Наталья Левчук
11. Дина Рабецкая
12. Евгений Петров
13. Дина Бикжанова
14. Наиля Монасыпова
15. Адиля Ибушева
16. Любовь Хакимуллина

Икенче скрипкалар төркеме

1. **Юлия Клыкова - икенче скрипкалар төркеме концертмейстеры**
2. **Гульмира Дыкина - концертмейстер ярдәмчесе**
3. Анжелика Ахматова
4. Ольга Ивлиева
5. Дарья Монасыпова
6. Джанбек Монасыпов
7. Айдар Латфуллин
8. Альфина Приходченко
9. Роман Рогив
10. Елизавета Луценко
11. Елена Кириллова
12. Ульяна Забегаева
13. Зульфия Сайкина
14. Зульфира Ахметова
15. Лариса Михеева

Альтлар төркеме

1. **Айдар Багаутдинов - альтлар төркеме концертмейстеры**
2. **Илья Субботин - концертмейстер ярдәмчесе**
3. Владимир Ершов
4. Андрей Сушков
5. Антон Жук
6. Кирилл Каримов
7. Гузелия Еникеева
8. Елена Подольская
9. Анна Толмачева
10. Искандер Каримов
11. Руфия Шигапова
12. Софья Сергеева

Виолончельләр төркеме

1. **Михаил Гринчук - виолончельләр төркеме концертмейстеры**
2. **Александр Дульнев- концертмейстер ярдәмчесе**
3. Михаил Приходцев
4. Альберт Шайхутдинов
5. Виктор Иванов
6. Альбина Елькина
7. Александр Храмов
8. Наталья Садртдинова
9. Светлана Семендуева
10. Юлия Сушко
11. Ильдар Булгар
12. Роза Асадуллина

Контрабаслар төркеме

1. **Марат Волков - контрабаслар төркеме концертмейстеры**
2. **Роман Ходыкин - концертмейстер ярдәмчесе**
3. Сергей Дмитриев
4. Павел Николаев
5. Юрий Дудчак
6. Юлия Монасыпова
7. **Тагир Мухутдинов - Татарстан Республикасының атказанган артисты**
8. Павел Харитонов
9. Павел Мальцев

Флейталар төркеме

1. **Венера Порфирьева - флейталар төркеме концертмейстеры, Татарстан Республикасының атказанган артисткасы**
2. **Андрей Большаков - флейталар төркемен көйләүче**
3. Андрей Костягин
4. Антон Дыкин - флейта-пикколо

Гобойлар төркеме

1. **Андрей Шубин - гобойлар төркеме концертмейстеры**
2. **Сергей Булычев - гобойлар төркемен көйләүче**
3. Игорь Авдеев
4. **Дмитрий Никитин - инглиз мөгез быргысы**

Кларнетлар төркеме

1. **Артур Мухаметшин - кларнетлар төркеме концертмейстеры, Татарстан Республикасының атказанган артисткасы**
2. Андрей Бабушкин
3. Ярослав Артемьев
4. Фагиль Гильманшин - бас-кларнет

Фаготлар төркеме

1. **Рамиль Сафин - фаготлар төркеме концертмейстеры**
2. **Константин Воронцов - фаготлар төркемен көйләүче**
3. Максим Аникин
4. Кирилл Газизов
5. **Василий Ластовка - контрафагот, Татарстан Республикасының атказанган артсты**

Валтоннар төркеме

1. **Сергей Антонов - валторн төркеме концертмейстеры**
2. **Алексей Соловьев - валторн төркемен көйләүче**
3. Иван Никитин
4. Родион Акулов
5. Азамат Давлетгареев
6. Константин Сушко
7. Дмитрий Бабинцев

Торбалар төркеме

1. **Денис Петров - торбалар төркеме концертмейстеры**
2. **Дмитрий Трубаков - концертмейстер ярдәмчесе**
3. **Ильнур Каримуллин - торбалар төркемен көйләүче**
4. Денис Лоншаков
5. Николай Алексеев

Тромбоннар төркеме

1. **Руслан Вәлиев - тромбоннар төркеме концертмейстеры**
2. **Никита Казаков - тромбоннар төркемен көйләүче**
3. Данил Ракин
4. Александр Гладышев - бас-тромбон

Торба

Дмитрий Любавин

Бәрмә уен коралары төркеме

1. **Константин Колесников - бәрмә кораллар төркеме концертмейстеры**
2. **Михаил Красничкин - концертмейстер ярдәмчесе**
3. Наталья Николаева
4. Антон Ольховский
5. Георгий Фортунатов
6. Михаил Косов

Арфалар

1. **Наталья Антонова - арфалар төркеме концертмейстеры**
2. Александра Ржавцева

Фортепиано

Эдуард Ахматов



LUCIANO – ЭТО УНИКАЛЬНАЯ КОНЦЕПЦИЯ СПА-КОМПЛЕКСА
ДЛЯ ВСЕЙ СЕМЬИ, ГАРМОНИЧНО ОБЪЕДИНЯЮЩАЯ В СЕБЕ
НЕСКОЛЬКО НАПРАВЛЕНИЙ:

• ОТЕЛЬ • СПА • БЬЮТИ КЛИНИКА • ФИТНЕС-ЦЕНТР • ДЕТСКИЙ КЛУБ • РЕСТОРАН

И КАЖДЫЙ НАЙДЕТ ЗДЕСЬ ИМЕННО ТО, ЧТО ЕМУ ПО ДУШЕ

LUCIANO
SPA • FITNESS • BEAUTY CLINIC • HOTEL

г. Казань, ул. Островского, 26
Тел.: +7 (843) 2000–900
luciano.ru luciano.spa

ПУШКИН
СКАЯ
КАРТА

Продажа билетов
в кассе ГАСО РТ

+7 (843) 236-79-71
+7 (843) 236-72-72
www.tatarstan-symphony.com

tatarstan_symphony

tatarstansymphony

tatarstan_symphony

tat_symphony

gsort

6+